# ДУСЛАРГА

*РОБЕРТ ТИМЕРБАЕВ көе*
*ӘСХӘР КӘШФУЛЛИН сүзләре*

Бала чакта сандугачтай
Килә иде сайрасы.
Мәхәббәтнең иң чибәрен
Килә иде сайласы.
Әле дә истә, әле дә истә
Балачак хыяллары.
Салават күпере кебек
Күңелем хыяллары..

*Кушымта:*
Сандугачым өйрәт мине,
Өйрәт мине сайрарга.
Сайрармын да, жырлармын да
Иң кәдерле дусларга.

Чәчәкле бала чалгымны
Жырлатам әле кайрап.
Сөюемне аңлатырга
Сандугач булып сайра.
Сандугачым сайра, сайра,
Сайра син арыганчы.
Сайра дилер халкым өчен
Йөрәгең ярылганчы.

*Кушымта:*
Сандугачым өйрәт мине,
Өйрәт мине сайрарга.
Сайрармын да, жырлармын да
Иң кәдерле дусларга.